**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 19 март | № 168

г. Казань

Шəхси милектə булган җир кишəрлеклəре мəйданын аларны Татарстан Республикасы милкендəге җир кишəрлеклəре яки дəүлəт милке чиклəнмəгəн җир кишəрлеклəре белəн яңадан бүлү нəтиҗəсендə арттырган өчен түлəү күлəмен билгелəү тəртибен раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{28}$ статьясындагы 5 нче пункт нигезендə, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Шəхси милектə булган җир кишəрлеклəре мəйданын аларны Татарстан Республикасы милкендəге җир кишəрлеклəре яки дəүлəт милке чиклəнмəгəн җир кишəрлеклəре белəн яңадан бүлү нəтиҗəсендə арттырган өчен түлəү күлəмен билгелəү тəртибен (карарга теркəлə) расларга.

2. Бу карарның үтəлешен тикшерүдə тотуны Татарстан Республикасының Җир һəм мөлкəт мөнəсəбəтлəре министрлыгына йөклəргə.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\168.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 19 март, 168 нче
карары белән расланды

Шәхси милектә булган җир кишәрлекләре мәйданын аларны Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә арттырган өчен түләү күләмен билгеләү тәртибе

1. Бу Тәртип шәхси милектә булган җир кишәрлекләре мәйданын аларны Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә арттырган өчен түләү күләмен (алга таба – түләү күләме) билгеләү кагыйдәләрен регламентлый.

2. Түләү күләме Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә карата милекче вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирүгә вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан хисаплап чыгарыла.

3. Түләү күләме Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенең яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлегенең аны шәхси милектәге җир кишәрлекләре белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милеккә бирелергә тиешле мондый җир кишәрлеге өлеше мәйданына пропорциональ рәвештә хисаплап чыгарылган кадастр кыйммәтенең 15 проценты буларак билгеләнә, моңа бу Тәртипнең 4 нче пунктында күздә тотылган очрак керми.

4. Татарстан Республикасы ихтыяҗлары яки муниципаль ихтыяҗлар өчен булдырылырга тиешле җир кишәрлекләрен алга таба алу максатларында җир кишәрлекләре яңадан бүленгән очракта, түләү күләме җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милеккә бирелергә тиешле Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлеге яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлеге өлешенең бәяләү эшчәнлеге турындагы законнарга таянып билгеләнгән базар кыйммәте нигезендә билгеләнә.

---